

1989 елнын февралендә Афганистаннан совет гаскәрләрен чыгару тогәлләнде. Ботен СССР кинлекләрендә уллары армия яшенә житкән әти-әниләр жинел сулап куйды, 9 ел да 1 ай һәм 18 кон барган сугышка нокта куелды. Бу коннәрдә әлеге вакыйгага 30 ел тулды. Афганистаннын канлы сабаклары онытылмаска тиеш.
Шулай, 12нче февральдә Ромоданово районы Алтар урта мәктәбендә якташ афганчыларына багышланган «Син хәтеремдә һәм йо-рәгемдә, Афганистан» дигән кичә vткәрәләр. Кичә бу теманы кин яктыртылган стендлар белән бизәлгән. Мәктәп укытучысы Наиль Хайдар улы Исхаков мәктәп һәм музей буенча экскурсия алып барган; истәлекле чыгыш ясаган.       Район ветераннары житәкчесе А.И.Родионов, военкомат хезмәткәре Л.П.Горбунова белән бергә район һәм авыл афганчылары, батырлар – Риан Амерханов, Фатих Байбулатов, Менир Ипкаев, Булат Сайфетдинов, Менир Чапаев, батырларча вафат булган Рафик Кадеркаевнын сенеле Талибә Манеева, батырларча вафат булган Менир Кузяевнын энесе Юнир Кузяев иде. Кичәдә барлыгы унбиш афганчы, укучылар, укытучылар, авыл кешеләре катнашты.
Әйтеп китәргә кирәк, барлыгы Ромодан районыннан 105 кеше Афганистанда барган сугышта катнашкан. Аларнын уналтысы - Алтар авылы кешеләре. Бу сугышта батырларча вафат булган Рафик Абдулла улы Кадеркаев белән Менир Мянсур улы Кузяевка альбом багышлаганнар. Тагы Алтар авылында батырларча һәлак булган сугышчы-интернационалистларга һәйкәл басып тора.
Биредә килгән кунаклар нотыг сойләгән, афганчыларга бvләкләр тапшырганнар. Афган сугышы ветераны Булат Сайфетдиновка, бvген хәрби хезмәттә булган улын патриот итеп тәрбияләгән очен, Мордовия Главасы Рәхмәт хаты тантаналы рәвештә тапшырганнар.
Чарада Алтар мәктәбенен һәрбер сыйныф укучысы әзерләп килгән концерт номеры янгыраган. Шулай ук Афган коточкыч сугышы турында жентекләп сойләп, кvргәзмәләрне карап, иншаларны укыганнар.
Афганчылар хәтерләрендә һәм йорәкләрендә саклаган истәлекләре белән уртаклашкан. Бу укучылар очен тагы бер патриотик тәрбия vрнәге булып тора. Яшь буын тыныч тормышнын кадерен, сугышнын нинди югалтуларга китерvен белеп vсәргә тиеш.